| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Табарлинского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Тәбәрле авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |

06.12.2023 Тәбәрле авылы № 37-1

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Тәбәрле авыл җирлеге Советының "Җир салымы турында" 20.11.2017 елның 30-1 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 394 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тәбәрле авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Тәбәрлеавыл җирлеге Советының "Җир салымы турында" 20.11.2017 елның 30-1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 9 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-Башка җир кишәрлекләренә карата 1,5 %.».

2. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Җир салымы турында» 20.11.2017 елның 30-1 номерлы Тәбәрле авыл җирлеге Советы карарына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тәбәрлеавыл җирлеге Советының 09.10.2023 елның 34-2 номерлы карарының 1 пунктындагы 1.1 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тәбәрлеавыл җирлегенең мәгълүмат стендында урнаштырырга, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (https://pravo.tatarstan.ru).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет
Табарлинского
сельского поселения
Төбәрле авыл
җирлеге Советы
ИНН 1601002519

Авыл җирлеге башлыгы Р.Р.САЛИМУЛЛИН
Совет рәисе